**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 45** **09.12.2021 ел.**

**2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1 статья

1. 2022 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 4189,0 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 4189,0 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 мең сум күләмендә.

2. 2023 һәм 2024 елларга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2023 елга 4203,2 мең сум, 2024 елга 4223,2 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2023 елга 4203,2 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 106,5 мең сум һәм 2024 елга 4223,2 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 209,7 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2023 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2024 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2025 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;

3 статья

Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетында 2022 елга, 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 кушымта нигезендә расларга.

2. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 елга 0 мең сум, 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

5 статья

1. Буш вакытны оештыру өчен шартлар тудыру һәм Александр Бистәсе авыл җирлегендә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен килешү нигезендә гамәлгә ашыруга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2022 елга 1980,6 мең сум, 2023 елга 1974,3 мең сум, 2024 елга 1990,4 мең сум итеп расларга.

2. 2022-2024 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6 статья

Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Зәй муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотацияләрне 2022 елда 1136,2 мең сум, 2023 елда 1146,9 мең сум, 2024 елда 1157,9 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

7 статья

Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетында Зәй муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 103,8 мең сум, 2023 елда 107,3 мең сум, 2024 елда 111,2 мең сум күләмендә дотация күләмен расларга..

8 статья

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александровка бистәсе авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Казначылык департаментының Зәй районы һәм Зәй шәһәре территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 статья

Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге исеменнән төзелгән, 2021 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар буенча төзелгән бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә 2022 елда Зәй муниципаль районы Александровка бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

11 статья

Әлеге карарны җирле массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге рәсми сайтында, «Авыл җирлекләре” бүлегендә урнаштырырга.

12 статья

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Александр Бистәсе авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Варганова Л.Г.**